# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

1943 нче елда туган



- Равиль Фәйзуллин 1943 нче елның 4 нче августында Татарстанның Балык Бистэсе районында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты факультетында белем ала. Биредә укыган чорда ук Равил Фәйзуллин шагыйрь буларак танылa.




- Равил Фәйзуллин – Татарстанның Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Татарстан Республикасының халык шагыйре.



- Шагыйрь балалар өчен дә яза. “Рәсем ясыйм”,”Чәчәкләр үстердем”, “Якты моң” исемле китаплары аның иҗатының үзенчәлекле өлешен тәшкил итәләр.



- Р. Фәйзуллин шигырьләренә күп кенә җырлар язылган. “Менә без дә үсеп җиттек, әни”,” Аккошлар”, “Сагыш” һәм башка җырларын тамашачылар яратып тыңлыйлар



- Шагыйрьнең күп кенә әсәрләре, рус теленнән тыш, башка милләт телләрендә дә, немец, француз, гарәп телләре кебек чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.



- Равил Фәйзуллинның публицистикасын туплаган китапларыннан берсе “Җырларда – ил гаме” дип атала. Анда ул әдәбият һәм сәнгатьнең мөһим мәсьәләләрен яктырта, төрле республикаларга һәм чит илләргә сәяхәтләреннән соң туган уйлары белән уртаклаша.



- Бүгенге көндә дә Равил Фәйзуллин заман сулышын тоеп яши, яңадан-яңа әсәрләр иҗат итә. Ул – “Казан утлары” журналының баш мөхәррире, танылган җәмәгать эшлеклесе



# Башаров Тимур 6 сыйныф укучысы А үтәгән